РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
18.02.2022

КАРАР
№ 4

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 08.11.2021 елның №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 08.11.2021 елның №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев

Кушымта
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Тимершык
авыл җирлеге Советының
18.02.2022 елның №4 карары
нигезендә

“Кушымта № 3
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Тимершык
авыл җирлеге чикләрендә
муниципаль торак контроле
турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

## 1. Муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре

1 таблица

| Төп күрсәткечләре | Максатчан әһәмият |
|---|---|
| Торак законнарын бозу очраклары арасыннан бетерелгән бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына пландагы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Муниципаль контроль органы һәм аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең проценты | 0% |
| Контроль чаралар нәтиҗәләренең бетерелгән проценты | 0% |
| Нәтиҗәле контроль чаралар проценты, алар буенча күрелмәгән тиешле административ йогынты чаралары | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми санынннан проценты | 0% |

## 2. Чаралар үткәрү параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр

2.1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә:

1) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралар саны;

2) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралар саны;

3) хисап чорында үткәрелгән үзара хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны;

4) хисап чорында үткәрелгән ККЧ һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү

буенча контроль чаралар саны;

5) хисап чорында дистанцион үзара тәэсир итүче чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

7) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

9) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;

10) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13)хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

14) хисап чоры азагына куркынычның һәр категориясе буенча куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларының исәпкә алынган объектлары саны;

15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның саны;

16) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән контрольдә тотылучы затларның саны

17) контроль органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләрнең саны хисап чорында;

18) контроль органнарның вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны хисап чорында;

19) контроль органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү турында дәгъва гаризалары саны, алар буенча хисап чорында бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителде;

20) муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылса яки хисап чорында юкка чыгарылса."